# Яшьлек

Минзәлә шәһәре гимназиясе

Киләчәкнең башы - бүгенгедә

1998

*Март 2017 ел*





## Ак калфак оешмасы

## Атна шәхесе - Ленар абый!



## Язгы ярминкә

# Нәүрүз



“Сабантуй”, “Нәүрүз”, “Каз өмәләре”, “Мәүлид кичәләре” – болар барысы да ел фасыллары белән бәйле булган тарихи бәйрәмнәр.Ә бүген исә Нәүрүз бәйрәме турында күбрәк белербез...

"Нәүрүз” сүзе фарсыча "яңа көн” дигәнне аңлата. Урта Азиядә, Иранда, Әфганстанда һәм кайбер башка илләрдә бик борынгыдан килгән Яңа елны каршылау бәйрәме ул. Нәүрүз көн белән төн тигезләшкән чорга – 21-22 мартка туры килә. IX гасырда Нәүрүз көннәрендә йорттан-йортка кереп "нәүрүз әйтеп” йөрү булган. Моны укучы балалар башкарган. Нәүрүз такмагын укып хуҗаларга бәхет, уңышлар теләп йөргәннәр. Балаларның болай йөрүе үзенә күрә бер күңел ачу булган: салкын кышлар бетеп килүенә шатлану, авыл халкының күңелен күтәрү. Бераз сыйланып алучылар да булган, чөнки нәүрүз әйтүләр беркайчан да бушка булмаган. Алар күчтәнәч, акча таләп иткәннәр. Ә авыл буйлап йөргәннән соң инде, җыелган күчтәнәчләрдән Сабантуй уздырганнар! Бергә җыелып, уеннар оештырганнар. Арадан иң чибәр, уңган кыз Нәүрүзбикә итеп сайланган. Җыелган халык "нәүрүз" җырлаган, бәетләр әйткәннәр. Нәүрүз көнне кеше күңелендә гел изгелек кенә булырга тиеш. Ул игелек булып, аның үзенә үк кире кайтачак. Яңа елны ничек каршыласаң, елың шулай үтәр, дип уйлау күңелләрдә өмет уяткан. Бәйрәм искиткеч матур үткән.



Безнең мәктәптә дә быел Нәүрүз бәйрәме гөрләп узды! Балалар Яз кызы белән күңел ачтылар, уйнадылар. Шулай итеп, без халкыбызның бу матур йоласын искә төшердек. Шулай ук безнең бәйрәмебезнең зур кунагы Су анасы булды. Ул - Сабир Өметбаев исемендәге татар дәүләт драма театры артисткасы, "Ак калфак" вәкиле, 1 нче сыйныфта укучы Булатның әнисе Чулпан Бәдертдинова. Чулпан апага моның өчен би-и-ик зур рәхмәт әйтәбез!





Җәмилова Айзилә

# Атна шәхесе - Ленар абый



Бу атнаның шәхесе- яраткан Ленар абыебыз! Ленар абый – “спортивный” күңелле һәм би-и-к ярдәмчел кеше. Ул безнең гимназиябездә инде күп еллар физкультура дәресләре һәм көрәш түгәрәген алып бара. Көрәш белән шөгыльләнгән егетләребез зур уңышларга ирешәләр, моның өчен без Ленар абыйга бик рәхмәтлебез.

**Туган көне : 8.03.77**
**Ф.И.О.: Заһриев Ленар Нур улы**
**Яраткан фильмы: фантастика**
**Яраткан ризыгы: бәрәңге**

**-Хәерле көн, Ленар абый!**
-Сәлам, Айзилә.
**-Тормышыгызда сезнең өчен нәрсә мөһим?**
-Иң беренче чиратта, гаилә.
**-Сезнең тормышыгызда берәр нинди “безбашенный” поступок бар идеме?**
-Юк, хәтерләмим.
**-Сез үзегезне уңышлы кеше дип саныйсызмы?**
- Әйе.
**-Нинди 3 әйбердән куркасыз?**
- Аллаһтан башка бернәрсәдән дә курыкмыйм (елмая)
**- “Эх туган көн, туган көн...” дигән җырны дәвам итегез.**
- 1 елга картайган көн.




**- Әгәр дә вакыт машинасына утырып, үткәнгә кайтып булса, сез нәрсә үзгәртер идегез?**
- Яшьтән үк Аллаһ кушканнарны эшләр идем мин.
**- Кечкенә чагыгызда нинди профессия сайлыйсыгыз килгән иде?**
- Шофёр булырга хыялланган идем (көлә), АМКАга укырга керәсем килкән иде.
**- Көрәш белән кайчан шөгыльләнә башладыгыз?**
- 4-нче сыйныфта, мәктәптә көрәш түгәрәгеннән башка түгәрәкләр юк иде, шуңа күрә анда йөри башладым.


Җәмилова Айзилә

# Язгы ярминкә



Беренче ярминкәләр Франция белән Англиядә киң таралган. Урта гасырларда ярминкәләр халыкта иң төп бәйрәм булып саналган. Анда төрле шәһәрләрдән сәүдәгәрләр , музыкантлар, гадалкалар җыелганнар. Шулай ярминкә халык өчен күңел юаткыч үзәк булып узган. Элек безнең Минзәләбезне сәүдәгәрлек шәһәре дип таныганнар. Минзәлә ярминкәсе күп шәһәрләргә билгеле булган, иң таралган товар булып, атлар саналган.



Өченче чиреккнең азагында гимназиядә беренче тапкыр Ярминкә уздырылды. Укучылар бәйрәмгә әти-әниләрен, әби-бабаларын һәм танышларын чакырдылар. Ярминкәдә төрле-төрле тәмле итеп пешерелгән ризыклар, матур кул эшләре сатылды. Кызыклы гына бер акция дә үткәрелде: сәхнәдә җырлаган укучыларга тамашачылар түбәтәйгә акча салдылар. Ярминкәдә эшләгән акчалар хәйриягә тотылды. Мәктәп тормышында мондый чаралар бик тә кирәк. Үзенә күрә дәресләрдән соң күңелгә бер ял булды ул.

*Шәрифуллина Рүзилә*

# Бәхет көне



Кешенең иң көчле теләге ул - бәхетле булу. Халыкара бәхет көне - шуны дәлилләүче бәйрәм. Бәхетле булу, тормыштан тәм табу өчен, үткәннәргә рәхмәтле булырга, хәзерге көнне яратырга, киләчәккә ышанырга кирәк. Халыкара бәхет көнендә бөтен ил күләмендә төрле чаралар үткәрелә. Хәтта кайбер илләрдә бу бәйрәм берничә атналарга сузыла. Туганнар һәм якын кешеләр үзләренең ратуларын белдерәләр. Хәтта үзара таныш булмаган кешеләр дә бер-берсенә көтелмәгән сюрпризлар ясыйлар. Әлеге бәйрәм - чын мәгънәсендә елмаю һәм бәхет көне, ә бу исә - һәрберебез нинди дә булса яхшылык эшли ала, галәмгә нindидер шатлык, сөенеч бүләк итә ала дигән сүз.





*Хәбирова Наилә*

# Ак калфак оешмасы

“Ак калфак” Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы 1990 елда барлыкка килә. Ул ана һәм бала хокукларын яклау; күп балалы гаиләләргә ярдәм итү; татар гаиләсен саклау аша татар милләтен үстерү; гореф–гадәтләрне, телне саклап калу; дөнья күләмендә барган икътисади һәм сәяси процессларда хатын-кызның ролен үстерү максатыннан оештырыла.

«Ак калфак» оешмасы үсеп килүче буында:

- милли үзаң формалаштыру;
- милли мәдәниятне һәм күпьеллык кыйммәтләрне торгызу, саклау һәм үстерү;
- туган телгә ихтирамны арттыру, татар мәктәпләренә һәм гимназияләренә ярдәм итү;
- милләтебезнең кием атрибутикаларын тегү–чигү һәм милли ризыклар әзерләү буенча мастер–класслар оештыру;
- ана, бала һәм ата хокукларын яклау буенча закон актларын әзерләүдә катнашу

һ.б. шундый эшләр башкара.



“Ак калфак” татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Татарстанда - 162 бүлекчәсе, Россия регионнарында – 36, чит илләрдә 18 бүлекчәсе оештырылды. Хәзерге вакытта “Ак калфак”ның 216 оешмасы һәм моннан тыш тарихта калган татар хатын-кызларыбыз исемнәре белән аталучы оешмалар да, безнең белән берлектә (“Сөембикә”, “Сәхибҗамал”, “Бубый”) милли юнәлештә уңышлы гына эшләп килә.

“Ак калфак” оешмасы безнең районыбызда да бик актив эш алып бара.Төрле очрашулар, һөнәрләргә өйрәтү буенча мастер-класслар үткәрә,хатын-кызларыбызны берләштереп матур гына чаралар оештыра, шулай ук кул эшләре һәм аш-сулар күргәзмәләрендә еш катнаша!



18 март көнне гимназиядә үткәрелгән язгы ярминкәдә “Ак калфак” оешмасы бизәкле, милли орнаментлы алкалар, беләзекләр, муенсалар һәм шулай ук калфакларын да безгә тәкъдим иттеләр. Аларның матурлыгын, нәфислеген күреп, барыбыз да хәйран калдык.




Шулай ук Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры артисткасы Ильсинә Миңнемуллина -“Ак калфак” оешмасының вәкиле- укучыларга сәйлән белән чигү буенча остаз дәресе уздырды. Дәрес дәвамында укучылар милли татар бизәкләренең тарихы, татар хатын-кызларының бизәнү әйберләре белән таныштылар. Милли бизәк - ул үзе бер тарих, аның һәркайсына нindидер мәгънә салынган бит! Балалар эшнең төп нечкәлекләренә төшенделәр, һәм бу дәрес аларга бик ошады.Укучылар чарадан канәгать калып: “Тагын килер идек”, – дип таралышты.

# Бәйрәм белән, кызлар!



Ни хикмәттер, күңелләр кара көздә дә, буранлы ак кышларда да язны сагына, язны юксына. Көткәнне белгән кебек, әйләнә дә килә язлар...Үзем дә сизмәдем, кичә генә буранлы салкын кыш, февраль ае иде, инде бүген март җиткән. Табигатьтә яңа үзгәрешләр: кояш бозларны ялаган, март аеның нечкә билле җиле, сузылып ятып җиргә кар ашаган, кошлар кайтыр юлга чыккан, карда юеш кара туфрак чыккан, агач кәүсәләре юешләнгән,тып-тып тамчылар тама... Дөньяга яз килә!



Без, кызлар, язны аеруча зарыгып көтәбез. Тиздән 8 Март- хатын-кызлар бәйрәме якыная. Тик без 8 Мартның хатын-кызларның тигез хокуклар өчен көрәшкәндә барлыклар килүеннән тыш нәрсә беләбез? Менә сезгә берничә кызыклы факт:

-8 Мартның төп символы - мимоза.

-8 Март көне, хатын-кызлар бәйрәменнән тыш, башка вакыйгаларның датасы да: бу көнне бөек Фёдор Фёдорович Ушаков, әкиятче Вильгельм Гримм, легендар актёр Андрей Миронов кебек кешеләр дөньяга килгән; ә 1618 елның 8 мартында планеталарның хәрәкәтенең 3-нче законы формалашкан.

Безнең мәктәптә дә 8 Март бәйрәме билгеләп үтелде, кызлар-әниләр арасында спорт бәйгесе уздырылды. Барлык катнашучылар үзләрен яхшы яктан күрсәттеләр, актив катнаштылар. Сынатмадыгыз, кызлар, әниләр! Афәрин!



Апа-сеңелләр, кызлар, дәү әниләр! Ихлас күңелдән сезне хатын-кызлар бәйрәме белән котлыйбыз! Сезгә корычтай нык сәламәтлек, ак бәхетләр, күңел тынычлыгы, иҗади уңышлар, мул тормыш һәм бары тик күңелле вакыйгалар гына телибез! Иң зур теләкләрегез, күптән көткән хыялларыгыз чынга ашсын, барлык өметләрегез аклансын, максатчанлык һәм тапкырлык сезгә гел юлдаш булсын!  Күңелләрегез көр, аяз, рухыгыз нык булса, сезгә бернинди бәла-каза да ишек какмас! Яңа үрләр яулагыз, белемгә омтылыгыз, дөньяны өйрәнегез, иң шәп мизгелләр алда көтә! Бәйрәмебез котлы булсын!

Сәхәбетдинова Регина

# Туган көн- гомер бәйрәме...



**Укытучылар:**
**Ленар Нурович (8.03)**
**Шәүкәт Рәшитович (14.03)**
**Марат Фәезович (18.03)**
**2 нче сыйныф:**
**Хәсәнов Инсаф (15.03)**
**3 нче сыйныф:**
**Исхакова Айзилә (22.03)**
**Сәлимова Айназ (21.03)**
**4 нче сыйныф:**
**Хәбирова Фирүзә (18.03)**
**5 нче сыйныф:**
**Каюмова Зилия (21.03)**
**Заһриев Ильяс (5.03)**
**6 нчы сыйныф:**
**Габдрахманова Диләрә (25.03)**
**Балакаев Эдвард (01.03)**
**Тәхәбиев Атлас (31.03)**
**7 нче сыйныф:**
**Фәрхетдинова Рузалина (31.03)**
**8 нче сыйныф:**
**Хәбирова Наилә (8.03)**
**Җәмилова Айзилә (21.03)**
**Шаматов Марат (25.03)**
**9 нчы сыйныф:**
**Сәләхова Зөһрә (30.03)**
**Гаянов Илшат (18.03)**
**Вилданов Асаф (17.03)**
**11 нче сыйныф:**
**Хәмитова Алинә (16.03)**



## Шулай ук...



18 нче март көнне безнең хөрмәтле директорыбыз Бәдриев Марат Фәез улының туган көне булып узды! Кадерле Марат Фәезович! Сезне ата-аналар, балалар, укытучылар һәм гимназиянең барлык эшчеләре исеменнән Туган көнегез зу-у-ур юбилеегыз белән котлыйбыз! Сезгә сәламәтлек, озын гомер, эшегездә иҗади уңышлар, гаилә бәхете, тыныч, имин көннәр телибез. Без Сезне бик хөрмәт итәбез, яратабыз!

**Баш мөхәррир** —Низамова Сөмбел
**Әдәби консультант-** Җәмилова Айзиля
**Бүлек мөхәррирләре** - Хәбирова Наилә
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official